ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вазыйфаларын башкарган затның тәҗрибәсеннән һәм белемнәреннән файдалану максатларында, аның Татарстан Республикасы законнарын, парламентара хезмәттәшлекне үстерүгә, республиканың һәм Россия Федерациясенең иҗтимагый-сәяси тормышында Татарстан Республикасы парламентының ролен ныгытуга керткән өлешен танып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе исемен гамәлгә куярга.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
урынбасары — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре
2026 елның 17 марты
№ 580-VII ДС

2026 елның 17 мартындагы
580-VII ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе турында нигезләмә**

1. Өч һәм аннан күбрәк чакырылышлар дәвамында вәкаләтләр башкарган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен туктатканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (алга таба – Дәүләт Советы) тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе (алга таба – Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе) итеп сайланырга мөмкин.

2. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисен сайлау турындагы тәкъдим белән Дәүләт Советы Президиумы, Дәүләт Советындагы фракцияләр, Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән береннән торган депутатлар төркеме чыгарга мөмкин.

3. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисен сайлау турындагы Дәүләт Советы карары, әгәр депутатларның билгеләнгән саныннан яртысыннан артыгы аны хуплап тавыш бирсә, кабул ителә һәм Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

4. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисенә таныклык тапшырыла, аның үрнәге һәм тасвирламасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан раслана.

5. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе үз эшчәнлеген түләүсез нигездә башкара.

6. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе түбәндәгеләргә хокуклы:

Дәүләт Советының, аның Президиумының, Дәүләт Советы комитетларының һәм комиссияләренең, Дәүләт Советы комитетлары каршындагы эксперт советларының, Дәүләт Советында төзелә торган башка коллегиаль органнарның барлык утырышларында, шулай ук парламент тыңлауларында һәм Дәүләт Советында үткәрелә торган башка чараларда киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга;

Дәүләт Советы, аның Президиумы, Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре, Дәүләт Советы комитетлары каршындагы эксперт советлары, Дәүләт Советында төзелә торган башка коллегиаль органнар утырышында, шулай ук парламент тыңлауларында һәм Дәүләт Советында үткәрелә торган башка чараларда чыгыш ясау өчен сүз алырга;

Дәүләт Советына мәҗбүри каралырга тиешле тәкъдимнәр җибәрергә;

Дәүләт Советы депутатларына бирелә торган документлар һәм материаллар, башка мәгълүмат алырга.

7. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе гавами хакимият органнары чакыруы буенча алар тарафыннан уздырыла торган федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәләрдәге чараларда катнашырга хокуклы.

8. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисенә Дәүләт Советының утырышлар залында махсус урын һәм Дәүләт Советы бинасында оргтехника һәм элемтә чаралары белән җиһазландырылган эш кабинеты, шулай ук хезмәт урыны буенча транспорт чарасы бирелә.

9. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе эшчәнлеге аның Дәүләт Советы Аппараты структурасына керә торган секретариаты тарафыннан тәэмин ителә.

10. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе эшчәнлеген, вәкиллекле функцияләрен дә кертеп, финанслау Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында Дәүләт Советы Аппаратын тотуга каралган чыгымнар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.